**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы**
**Масловка авыл җирлегенең торак пунктында гражданнар җыены**
**нәтиҗәләре турында**

# КАРАР

3 декабрь, 2021 ел № 3

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Уставына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Советының 2019 елның 16 октябрендәге XIII номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге составына керүче торак пунктында гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Башлыгының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлегенең Масловка авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” 2021 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы карары нигезендә, 2021 елның 3 декабрендә узган гражданнар җыенының 5 нче номерлы йомгаклау беркетмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлегенең Масловка авылы торак пункты гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлегенең Масловка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 1 төркем инвалидлар, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә. Тупланган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Масловка авылының Үзәк урамы буенча коймаларны ремонтлау;
- Масловка авылының 2 шт. күләмендә тирән насослар сатып алу һәм урнаштыру;
- Масловка авылы зиратында урамнарны һәм юлларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу;
- Масловка авылы зиратында юлларны һәм урамнарны төзекләндерү өчен вак таш ташу буенча транспорт хезмәтләре өчен түләү;
- Масловка авылы урамнарының машиналар йөрү өлешен кышкы карап тоту (урамнарны чистарту) ;
- Заовражная урамы буенча елга аша күперне ремонтлау;
- Масловка авылы урамнарыннан чүп үләннәре чабу һәм юлларны җәй көне карап тоту һәм 2 контейнер мәйданчыгы-урнаштыру;

- Масловка авылы суүткәргечен ремонтлау.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка җирлегенең Масловка авылы, Узәк урам, 13 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында” урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче –
Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Масловка авыл җирлеге Башлыгы А.И.Егоров